**СОВЕТ ТАТАРСКО - ЯНТЫКСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422634 с.Татар Янтык,
ул. Магазинная, д 31 а
Тел/факс 8-(378) -3-26-21

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ТАТАР ЯНТЫГЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

422634 Татар Янтыгы авылы,
Кибет урамы, д 31а йорт
Тел/факс 8-(378) -3-26-21

№13 **2019 елның 7 октябреннән**

## РЕШЕНИЕ

## КАРАР

**"Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Татар Янтыгы авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында” Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Татар Янтыгы авыл җирлеге Советы карары проекты хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы һәм «муниципаль берәмлекләр уставларын дәүләт теркәвенә алу турында» 21.07.2005 елдагы 97-ФЗ номерлы Федераль законнар, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татар Янтыгы авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Кушымта нигезендә Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Татар Янтыгы авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр кертергә.
2. Әлеге карарны «Камская новь» («Кама ягы») район газетасында, махсус мәгълүмат стендларында һәм интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге адрес буенча бастырып чыгарырга (игълан итәргә): http://pravo.tatarstan.ru.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татар Янтыгы авыл җирлеге Башлыгы, Совет рәисе Р.М. Шәмеевкә йөкләргә.

**Татарстан Республикасы**
**Лаеш муниципаль районы**
**Татар Янтыгы авыл җирлеге**
**Башлыгы, Совет рәисе** **Р.М.Шәмеев**

**Татарстан Республикасы**
**Лаеш муниципаль районы**
**Татар Янтыгы авыл җирлеге**
**Советының 2019 елның 7 октябрендәге**
**13 номерлы карарына Кушымта**

## “Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Татар Янтыгы авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр”

23 статьяның 9 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә: «9. «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 статьясында каралган гражданнар җыены анда әлеге торак пунктта яшәүчеләрнең сайлау хокукына ия булган яртысыннан артыграгы катнашуда вәкаләтле, әлеге Устав нигезендә гражданнар җыены Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Татар Янтыгы авылында гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында Нигезләмә белән расланган тәртиптә гражданнар җыенын үткәрү турында Карар кабул ителгән көннән бер айдан да артмаган вакыт эчендә уздырыла. Шул ук вакытта элек гражданнар җыенында катнашкан затлар тавыш бирүдә киләсе этапларда катнашмый.»